| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МЕНЗЕЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНЗӘЛӘ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 июля 2019 г. г.Мензелинск № 1

**Татарстан Республикасы**
**Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең мәҗбүри дәүләт иминияте турында Нигезләмәсен раслау турында**

2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы №25-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексы нигезендә, Минзәлә муниципаль район Уставын кулланып, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең мәҗбүри дәүләт иминияте турында Нигезләмәсен расларга.
2. Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны "Интернет" мәгълүмати-коммуникацияле челтәрендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Гамәлдәге карар рәсми төстә басылган көннән үз көченә керә.
4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районының икътисад, бюджет һәм даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе А.Ф.Сәлахов

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район Советы
Карары белән
расланган
дата____№_____

## Татарстан Республикасы
## Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең мәҗбүри дәүләт иминияте турында
## Нигезләмәсе

1. Гамәлдәге Нигезләмә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракка муниципаль хезмәткәрләрнең сәламәтлегенә һәм тормышына мәҗбүри дәүләт иминияте буенча түләүләр очракларын, күләмен һәм тәртибен (алга таба – мәҗбүри дәүләт иминияте) билгели.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә муниципль хезмәткәр вазыйфасына билгеләнгән көннән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгән көнгә кадәр исәпләнә торган муниципаль хезмәт узган бөтен чор дәвамында мәҗбүри дәүләт иминияте уздырылырга тиеш.

3. Муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт уза торган җирле үзидарә органнары һәм башка муниципаль органнар мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминиятләүче булып торалар (алага таба – иминиятләүчеләр).

4. Мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыруга лицензиясе булган иминият оешмалары мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминиятләүче (алга таба – иминиятләүчеләр) була алалар.

Иминиятләүчеләрне сайлау дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен хезмәтләр, эшләр, торвалар сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе кануннарында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5. Иминиятләү килешүе Россия Федерациясе кануннарында каралган тәртиптә тәүлектәге 24 сәгать дәвамында иминият сакланышы белән бер календарь елга срок белән иминиятләнгән зат (иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өченче зат) файдасына иминиятләнүче һәм иминиятләүче арасында төзелә.

Гамәлдәге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән иминиятләү очраклары өчен иминиятләү килешүендә иминиятләүче тарафыннан иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өченче зат даирәсе билгеләнә.

Иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өченче зат сыйфатында иминиятләү килешүендә иминиятләүче тарафыннан түбәндәгеләр мәҗбүри тәртиптә аталырга тиеш:

иминиятләнгән затның үлгән көненә аның белән теркәлгән никахта торучы ире (хатыны);

иминиятләнгән затның ата-анасы (уллыкка алучысы), иминиятләнгән затның әбисе һәм бабасы – аның ата-анасы булмаган очракта, әгәр алар аны кимендә өч ел тәрбияләгән һәм караган булса;

иминиятләнгән затның үги әтисе һәм үги әнисе – әгәр алар аны кимендә биш ел тәрбияләгән һәм караган очракта;

иминиятләнгән затның 18 яшькә җитмәгән яисә бу яшьтән өлкән (әгәр дә алар 18 яше тулганчы инвалид булсалар), шулай ук укулары тәмамланганчы аларның оештыру-хокукый формалары һәм хосусыйлык формаларына бәйсез рәвештә белем бирү оешмаларында укучы балалары (әмма яше 23 яшьтән артырга тиеш түгел);

иминиятләнгән затның опекага алынучылары.

Иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өченче затлар аның иминиятләүчесе билгеләгән тәртиптә гражданлык хезмәткәре тапшыра торган мәгълүмат нигезендә иминият килешүендә күрсәтеләләр.

Иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өченче затларны күрсәтү кирәк булмаган очракта, гражданлык кануннарында билгеләнгән тәртиптә иминиятләнгән затның варислары иминиятләү килешүендә иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өченче зат итеп танылалар.

6. Муниципаль хезмәткәрне төзелгән иминият килешүенең гамәлдә булу срогы чыкканчы муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итү муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итү датасыннан күрсәтелгән муниципаль хезмәткәргә карата аның гамәлдә булуын туктатуга китерә.

Күрсәтелгән нигезләмә буенча муниципаль хезмәткәргә карата иминият килешүенең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, гамәлдәге Нигезләмәнең 12 пунктында билгеләнгән тәртиптә, иминиятләүче әлеге муниципаль хезмәткәргә карата иминият килешүе гамәлдә булуның калган срогына пропорциональ өлешендә әлеге муниципаль хезмәткәрнең иминиятләү белән бәйле рәвештә түләнгән иминият премиясен кире кайтара.

7. Түбәндәгеләр иминиятләү очрагы дип санала:

1)муниципаль хезмәт узганда иминиятләнгән затның үлеме, шулай ук муниципаль хезмәт узган чорда алган имгәнү, травмалар яисә авырулар нәтиҗәсендә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасыннан азат ителгәч, бер ел дәвамында;

2)муниципаль хезмәт узган чорда иминиятләнгән затка инвалидлык билгеләнү, шулай ук муниципаль хезмәт узган чорда алган имгәнү, травмалар яисә авырулар нәтиҗәсендә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасыннан азат ителгәч, бер ел дәвамында;

3) иминиятләнгән затның муниципаль хезмәт узган чорда имгәнү яисә травама алуы;

4) иминиятләүче затның эшкә яллаучы вәкилнең инициативасы буенча хезмәт конрактын өзүгә нигез булган авыруга дучар булуы (муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башкарган вазыйфасыннан азат итеп һәм инвалидлык билгеләнү белән бәйсез медицина йомгаклавы нигезендә сәламәтлеге начар булуга бәйле рәвештә эшеннән азат итү белән).

8. Иминиятләнгән затларга (иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өчен затларга) түләнә торган иминиятләү суммалары күләме муниципаль хезмәтнең алар башкарган вазыйфасы һәм муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата түләү оклады (алга таба – оклад) булган класслы чин өчен айлык өстәмә түләү нигезендә, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладыннан чыгып билгеләнә.

9. Иминият очраклары житкәндә иминият суммалары түбәндәге күләмдә түләнә:

1) иминиятләнгән затның муниципаль хезмәт узган чорда үлеме, шулай ук муниципаль хезмәт узган чорда алган имгәнү, травмалар яисә авырулар нәтиҗәсендә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасыннан азат ителгәч, бер ел дәвамында – окладның 26,25 өлеше. Күрсәтелгән иминият суммасы иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өчен затларга тигез өлешләрдә түләнә;

2) муниципаль хезмәт узган чорда иминиятләнгән затка инвалидлык билгеләнү, шулай ук муниципаль хезмәт узган чорда алган имгәнү, травмалар яисә авырулар нәтиҗәсендә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасыннан азат ителгәч, бер ел дәвамында:

I төркем инвалидка – окладның 17,5;

II төркем инвалидка – окладның 12,25;

III төркем инвалидка – окладның 10,5.

3) иминиятләнгән зат муниципаль хезмәт узган чорда авыр имгәнү һәм травма алган очракта – җиде оклад, җиңелчә имгәнү яисә травма – окладның 1,75.

Аларны алганда тиешле иминият суммасы түләнә торган имгәнү һәм травманы авыр яисә җиңел категориягә кертү 1998 елның 28 мартындагы “Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының, Янгынга кары дәүләт хезмәтенең, җәзаларны үтәтү системасы органнары һәм учреждениеләре хезмәткәрләренең, Россия Федерациясенең милли гвардия гаскәрләре хезмәткәрләренең рядовой һәм начальник составы затларының, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнарның, хәрби хезмәттәегләрнең тормышын һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминиятләве турында”гы №52-ФЗ Федераль законы нигезендә билгеләнгән авыр яисә җиңел булып саналучы имгәнүләр (яралану, травма алу, контузия) исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла;

4) иминиятләүче затның эшкә яллаучы вәкиленең инициативасы буенча хезмәт конрактын өзүгә нигез булган авыруга дучар булган очракта (муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башкарган вазыйфасыннан азат итеп һәм инвалидлык билгеләнү белән бәйсез медицина йомгаклавы нигезендә сәламәтлеге начар булуга бәйле рәвештә эшеннән азат итү белән) – окладның 8,75.

Әгәр муниципаль хезмәт узган чорда яисә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел узганчы иминиятләнгән затка федераль учреждениедә медик-социаль экспертиза кабаттан уздырылганда инвалидлык төркеме арттырылса, иминият суммасы күләме моңа кадәр инвалидлык төркеме буенча тиешле окладлар саны белән яңадан билгеләнгән инвалидлык төркеме буенча тиешле окладлар саны аермасыннан торган суммага арта.

Әгәр иминиятләнгән затка иминият очрагы белән бәйле рәвештә иминият суммасы түләнгән булса, ләкин иминият очрагы килеп туган көннән бер ел эчендә һәм турыдан-туры шуңа бәйле рәвештә аның сәламәтлеге начарланса яисә үлем очрагында, моңа кадәр түләнгән иминият суммаларын чигереп өстәмә иминият түләүләре (иминият суммалары) башкарыла

Һәр иминиятләнгән зат өчен түләнә торган иминият премиясенең күләме иминият килешүе белән билгеләнә һәм иминиятләнгән затның иминият килешүе төзелгән мизгелгә билгеләнгән окладының 8,75 процентыннан артык була алмый.

10. Иминиятләүче мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминият суммасын түләүдән түбәндәге очракларда азат ителә:

1) әгәр иминият очрагы иминиятләнгән зат тарафыннан суд билгеләгән тәртиптә җәмгыять өчен куркыныч дип танылган гамәл кылган өчен килеп чыккан булса;

2) иминиятләнгән затның алкоголь, наркотик һәм агулы матдәләрдән исерүе нәтиҗәсендә суд тарафыннан турыдан-туры сәбәп дип билгеләнгән;

3) иминиятләнгән затның үз сәламәтлегенә белә торып зыян салуы яисә иминиятләнгән затның үз-үзенә кул салуы суд тарафыннан расланган нәтиҗә булып тора.

Әгәр иминиятләнгән затның үлеме суд тарафыннан дәлилләнгән үз-үзенә кул салуга мәҗбүр итү нәтиҗәсе булса, иминиятләүче иминият суммасын түләүдән азат ителми.

Иминият суммасын түләүне кире кагу турында карар иминиятләүче тарафыннан кабул ителә һәм иминиятләнгән затка (иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өчен затларга) һәм иминиятләүчегә иминият суммасын түләүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән срокны кире кагуның мәҗбүри дәлилләнгән нигезләмә белән язма формада кабул ителә.

11. Иминият түләүләрен гамәлгә ашыру иминиятләнгән затның (иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өчен затның) гаризасы һәм иминиятләнүче тапшырган иминият очрагы җитүен раслаучы документлар нигезендә иминиятләүче тарафыннан башкарыла.

Иминият түләүләрен гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге, аларны бирү һәм карау тәртибе иминият килешүе белән билгеләнә.

Иминият суммаларын түләү иминиятләнгән затларга башка төр иминият килешүләре буенча тиешле суммаларга бәйсез рәвештә башкарыла.

Иминият суммалары иминиятләнгән затларга (иминият очрагында акчалата түләүне алырга хокуклы өчен затларга) иминият килешүендә билгеләнгән ысул белән тиешле суммаларны сумнарда күчерү юлы белән түләнә.

Иминият суммаларын түләү иминиятләүче тарафыннан күрсәтелгән түләү турында карар кабул итү өчен кирәкле документларны алган көннән соң 10 көн эчендә башкарыла.

12. Әгәр иминият килешүенең гамәлдә булу срогы дәвамында иминиятләнгән затларның оклад күләмнәрендә, шулай ук аларның санында үзгәрешләр булса, күрсәтелгән вазгыятькә бәйле рәвештә, алынып бетмәгән яисә артыгы белән алынган иминият взносы суммалары өстәп түләнергә яисә кире кайтарылырга тиеш.

Иминият килешүен төзегән яклар килешүе буенча күрсәтелгән суммалар иминият килешүе гамәлдә булуның чираттагы чорына иминият взносларының күләмен билгеләгәндә исәпкә алынырга мөмкин.

Иминиятләүче тарафыннан иминият взносларын кертүнең вакыт арасы иминиятләү килешүе белән билгеләнә.

13. Мәҗбүри дәүләт иминиятенә чыгымнарны финанслау муниципаль берәмлек бюджеты чаралары хисабыннан гамәлгә ашырыла.